ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Советская, д.62, с. Татарские Бурнашевы,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет ур., 62 нче йорт, Татар Бурнашы авылы,

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

с. Большие Меми

25.03.2020 | 5

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге торак пунктларының территорияләрен
санитар-экологик чистарту буенча икеайлык үткәрү турында

Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегенең торак пунктларын төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен оештыру һәм халыкның экологик иминлегенә җавап бирә торган халәткә китерү, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 4 мартындагы 157 номерлы карарын үтәү өчен

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Олы Меми авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту икеайлыгын игълан итәргә (алга таба – икеайлык).
2. 2020 елга Олы Меми авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составын расларга (1 кушымта).
3. 2020 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Олы Меми авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү буенча чаралар планын расларга (2 кушымта).
4. Олы Меми авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләренә, милек формасына карамастан, якын-тирә территорияләрне санитар чистарту эшен оештырырга, икеайлык кысаларында оештырылган полигонга һәм чүплеккә каты көнкүреш калдыклары чыгару өчен йөк транспорты бүлеп бирергә тәкъдим итәргә. Урыннарда агачлар һәм куаклар утырту, биналарның фасадларын, балалар мәйданчыкларын ремонтлау эшен оештырырга.
5. Нинди хокукка карамастан, авыл җирлеге территориясендә күчемсез милек булган гражданнарга йорт яны территорияләрен санитар чистарту буенча эш үткәрергә тәкъдим итәргә.
6. Бу карарны Олы Меми авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка игълан итәргә.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге
башлыгы Г.А. Фомина

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 25 мартындагы
5 номерлы карарына
1 кушымта

Олы Меми авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составы

1. Фомина Галина Александровна – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге башлыгы.
2. Сальцинова Анна Александровна– Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге Башкарма комитеты сәркатибе
3. Федоров Василий Петрович – Олы Меми авыл җирлеге участок инспекторы
4. Сальцинова Татьяна Михайловна – Олы Меми ФАП фельдшеры.
5. Сычева Ольга Геннадьевна – Олы Меми урта мәктәбе директоры.
6. Скарлухин Николай Александрович – Олы Меми сайлау округы депутаты.
7. Галикбаров Рафик Гашигуллович – Заборно- Полянский сайлау округы депутаты.

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге
башлыгы Г.А. Фомина

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 25 мартындагы
5 номерлы карарына
2 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге территориясендә 2020 елгы икеайлык кысаларында санитар-экологик хәлне яхшыртуга юнәлдерелгән төзекләндерү һәм санитар чистарту чаралары ПЛАНЫ

Т.б. №	Чараның исеме	Үткәрү датасы	Җаваплылар
1.	Олы Меми авыл җирлеге территориясендә чүплекләрне ачыклау һәм бетерү	01.04.2020 - 01.05.2020	Олы Меми авыл җирлегенең Башкарма комитеты
2.	Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчылар һәйкәлен төзекләндерү	20.04.2020 - 06.05.2020	Олы Меми авыл җирлегенең Башкарма комитеты
3.	Олы Меми авыл җирлеге буенча торак пунктлар эчендә баганалар агарту	Май	Олы Меми авыл җирлегенең Башкарма комитеты
4.	Шәхси торак йортларның йорт яны территорияләрен җыештыру	даими	Олы Меми авыл җирлегенең Башкарма комитеты
5.	Зиратлар территорияләрен төзекләндерү	Май	Олы Меми авыл җирлегенең Башкарма комитеты, яшәүчеләр
6.	Чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту	Май	Олы Меми авыл җирлегенең Башкарма комитеты
7.	Урамнарны яктырту (ремонт, өстәмә яктырткычлар урнаштыру)	Май	Олы Меми авыл җирлегенең Башкарма комитеты
8.	Олы Меми авыл җирлеге торак пунктларында яшел үсентеләр утырту	Май	Олы Меми авыл җирлегенең Башкарма комитеты
9.	Клумбалар ясау һәм ремонтлау, чәчәкләр утырту	30.05.2020 елга кадәр	Олы Меми авыл җирлегенең Башкарма комитеты, оешмалар
10.	Юл кырыйларын һәм юл буйларын чабу	даими	Олы Меми авыл җирлегенең Башкарма комитеты
11.	Урамнарны грейдирлау, юл кырыйларын һәм юл буйларын чабу	20.05.2020 елга кадәр	Олы Меми авыл җирлегенең Башкарма комитеты